ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 36-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 36-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 145-VII ДС

Проект

Татарстан
Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, №12 (I өлеш); 2010, №7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыентыгы, 2018, №83 (I өлеш); 2019, №79 (I өлеш); 2020, №57 (I өлеш); 2021, №57 (I өлеш), №77 (I өлеш)) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«4. Агымдагы финанс елына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме һәм агымдагы финанс елына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга і-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме агымдагы финанс елының 1 ноябренә әлеге Методиканың 3 пунктындагы алтынчы – уналтынчы, унтугызынчы – егерме өченче, егерме алтынчы һәм егерме җиденче абзацларында билгеләнгән күрсәткечләрнең фактик күрсәткечләрдән чыгып үзгәртелергә мөмкин.

Агымдагы финанс елына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү һәм агымдагы финанс елына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга і-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләмен исәпләп чыгару, әлеге пункт нигезләмәләрен исәпкә алып, әлеге Методиканың 2 һәм 3 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА ЯЗУЫ**

Әлеге закон проекты «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 123-ТРЗ номерлы Закон) белән расланган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләү методикасына үзгәрешләр кертүне күздә тота.

Гамәлдәге методика агымдагы финанс елында субвенцияне исәпләү өчен агымдагы финанс елының 1 ноябренә юлда йөрүләрнең (транзакцияләрнең) фактагы уртача айлык исәбеннән чыгып кулланыла торган күрсәткечләр үзгәрүенә бәйле рәвештә актуальләштерүне таләп итә.

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирү өчен субвенцияләр күләмен гамәлдәге методика нигезендә исәпләп чыгару чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләме билгеләнә торган елга кадәрге булган ел өчен фактик күрсәткечләрдән чыгып башкарыла.

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 20 мартындагы 210 номерлы карары белән расланган Тәртип нигезендә агымдагы финанс елында субвенцияләр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына фактагы күрсәткечләрдән, шул исәптән Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Җайга салынулы тарифларны билгеләү тәртибе нигезендә билгеләнгән иң чик максималь тарифтан чыгып бирелә.

Методиканы үзгәртү агымдагы финанс елының 10 аендагы фактик күрсәткечләрдән чыгып, гражданнарның ташламалы категорияләрен йөртүдән алынмый калган керемнәрне компенсацияләүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

**«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – ТР бюджеты турында закон) Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субвенцияләр 2024 елга гомуми 1 123 602,9 мең сум күләмендә каралган.

2024 елга субвенция күләме Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 2023 елда «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару методикасы нигезендә 2022 ел өчен фактик күрсәткечләрдән чыгып исәпләнде.

Агымдагы елның 10 аенда транзакцияләрнең фактик саны үзгәрү һәм агымдагы финанс елына максималь чик тарифлар үзгәрү сәбәпле, 2024 елда субвенцияләрнең гомуми күләме 1 314 942,1 мең сум тәшкил итә.

Законны кабул итү 191 339,2 мең сум күләмендә өстәмә акча бүлеп бирүне таләп итә.